**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2023-2024 учебный год**
**8 КЛАСС**

**Таблица ответов**

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **а** | | | | | **X** | | | | | | | **X** | | | | **X** | | **X** | | **X** |
| **ә** | **X** | **X** | | **X** | | **X** | | **X** | | | | | **X** | | | | **X** | | **X** | |
| **б** | | | | | | | **X** | | **X** | **X** | | | | **X** | | | | | | |
| **в** | | | **X** | | | | | | | | **X** | | | | **X** | | | | | |
| | ***задания по 1 баллу*** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

1. Гомумиләштерүче сүз булган җөмләне күрсәтегез. (1 балл)
а) Карлыган һәм кура җиләгеннән кышка кайнатмалар әзерлиләр.
**ә) Алма, груша, карлыган, слива – барысы да җиләк-җимеш.**
б) Татарстан урманнарында каен, карама, усак, имѐн һәм башка агачлар үсә.
в) Сандугач үзе кечкенѐ булса да, тавышы бик матур.

2. Миңа да, яшәү, иҗат итү өчен, авылым суы, авылым һавасы кирәк (М. Мәһдиев) җөмләсендәге аерымланган хәлнең төрен билгеләгез. (1 балл)
а) рәвеш хәле;
**ә) сәбәп хәле;**
б) максат хәле;
в) күләм хәле.

3. Кем нур сипсә, кем тир түксә,
Шуның кулы әйләндерә җир шарының күчәрен (С. Сөләйманова)
җөмләсендә ничә хәбәрлек бар? (1 балл)
а) 4;
ә) 5;
б) 2;
**в) 3.**

4. Шигырьдә сингармонизм законының 2 төре дә күзәтелә торган ничә сүз бар? (1 балл)
Әни сөртә иртән көзгеләрне,
Уйчанланып кала күзләре:
Еллар инде узган;
Хәтер офыгыннан;
Йөгереп үтә яшьлек эзләре.
(Р. Акъегет)
а) 5;
ә) 3
б) 4
**в) 2.**

5. Кайсы җөмләдә боерык фигыль кулланылган? (1 балл)
**а) Әгәр бүген вакытың булса, Фатих Кәримнең шигырьләрен алып укы.**
ә) Барыгызны да Туфан Миңнуллин иҗатына багышланган кичәгә чакырабыз.
б) Күренекле шагыйрь Сибгать Хәким халыклар дуслыгы турында күп язган.
в) Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы буенча тулы метражлы кинофильм төшерелде.

6. Оештыручы үзәге бер генә булган һәм икенчесен өстәп булмый торган җөмлә – (1 балл)
а) ким җөмлә;
**ә) бер составлы җөмлә;**
б) гади җөмлә;
в) тулы җөмлә дип атала.

7. Кайсы алынма сүздә ике иҗекле тартым кушымчасының беренче иҗеге нечкә, икенчесе калын була? (1 балл)
а) шигърият;
ә) спектакль;
**б) повесть;**
в) дикъкать.

8. Ясагыч кушымча белән ясалган сүзләр рәтен күрсәтегез. (1 балл)
а) барган, килде, ап-ак;
**ә) табышмак, акчалата, яхшылык;**
б) бәрәңге, көзгегә, җирләр;
в) һәркем, белмәгән, укыгач.

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (1 балл)
Җил истеме, **шыбыр-шыбыр** чикләвекләрен коя имән. (Шәүкәт Галиев)
а) фигыль;
ә) бәйлек;
**б) аваз ияртеме;**
в) рәвеш.

10. Искергән сүзләрдән торган рәтне билгеләгез. (1 балл)
а) белем, яфрак, миләүшә, энҗе чәчәк;
ә) клип, флешмоб, имидж, факс;
**б) чулпы, чабата, гакыл, ошбу;**
в) авыл, мәйдан, җир, агач.

11. Аббревиатура ул –(1 балл)
а) авазларның бер-берсенә җайлашуы;
ә) берәр аваз яки иҗекнең төшеп калу күренеше;
б) бер тартык авазның икенчесенә тәэсир итүе;
**в) кыскартылма сүз.**

12. Модальлек кушымчалары булган сүзләр рәтен билгеләгез. (1 балл)
**а) дуслар, кошчык, кызгылт, бишәр;**
ә) укыйлар, капчык, тилгән, акбур;
б) урамга, юлдаш, көннәрем, дустым;
в) кояшлы, язгы, бару, киләчәккә.

13. Хәл фигыль –(1 балл)
а) эш, хәл, хәрәкәтнең булуын яки булмавын хәбәр итә;
**ә) төп фигыльдән аңлашылган эш яки хәлгә өстәмә эшне белдерә;**
б) эш кушуны, чакыру, өндәүне белдерә;
в) эш яки хәлне максат кую, ниятләү мәгънәсендә белдерә.

14. Парлы саннар –(1 балл)
а) микъдар саны төркемчәсенә керә;
ә) бүлем саны төркемчәсенә керә;
**б) чама саны төркемчәсенә керә;**
в) өлеш саны төркемчәсенә керә.

15. Тәкъдим ителгән сүзләр лексикологиядә ничек атала? (1 балл)
Туп ал – тубал, су –кырларны – сукырларны, зур аю – зураю, алты ай – Алтай.
а) саф лексик омонимнар;
ә) омофоннар;
б) омографлар;
**в) омоформалар.**

16. Әсәрнең исемен, авторын билгеләгез. (1 балл)
“И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!
Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.”
**а) Г. Тукай “Пар ат”**
ә) Г. Тукай “Бер татар шагыйренең сүзләре”
б) С.Рәмиев “Мин”
в) Ш. Бабич “Халкым өчен”

17. ”Яшь бала елый иде...”. Кайсы әсәр шушы җөмләдән башлана? (1 балл)
а) Г. Ибраһимов “Алмачуар”
**ә) Ш.Камал “Буранда”**
б) Г.Кутуй “Сагыну”
в) Ф.Хөсни “Сөйләнмәгән хикәя”

18.”Кеше китә-җыры кала” әсәренең авторы кем? (1 балл)
**а) М.Мәһдиев**
ә) Ш.Камал
б) Г.Кутуй
в) Ф.Хөсни

19.Бакый Урманче ул-(1 балл)
а) композитор
**ә) рәссам**
б)  шагыйрь
в)язучы

20.Туфан Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” әсәренең жанры: (1 балл)
**а) драма**
ә) хикәя
б) шигырь
в) поэма

**II.** Сүз уртасында **һ** булган биш хәрефле исемнәр языгыз.**(10 балл)**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |
| | | **һ** | | |

**III. Иҗади бирем (10 балл)**

Син, әнием, минем өчен
Бу дөньяда бер генә.
Елмайганда йөзләреңнән
Бар өйгә нур бөркелә.
(Р. Миңнуллин)

Ә сез әниегез турындагы хис-тойгыларыгызны ничек җиткерер идегез? Фикерләрегезне 10 җөмләдән торган шигъри яки чәчмә текст итеп языгыз.

Иҗади биремне бәяләү критерийлары:

1. Язма эшнең эчтәлеге темага туры килә – 2 балл

Язма эшнең стуктур элементлары (кереш өлеше, төп өлеше, нәтиҗә) төгәл күрсәтелгән - 3 балл

2. Орфографик хаталар 1-2 күп түгел- 2 балл
3. Пунктуацион хаталар 1-2 күп түгел – 1 балл
4. Логик хаталар юк- 1 балл
5. Фактик хаталар юк – 1 балл